**Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 9-2 «29» сентябрь 2025 ел

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2006 елның 13 октябрендәге 48-8 номерлы «Азнакай шәһәрендә муниципаль махсуслаштырылган торак фондының махсуслаштырылган торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү тәртибе һәм муниципаль махсуслаштырылган торак фондында хезмәт урыннары бирелә торган гражданнар категорияләрен билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Гражданлык Кодексының 217 статьясы нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Азнакай шәһәре Советы карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2006 елның 13 октябрендәге 48-8 номерлы «Азнакай шәһәрендә муниципаль махсуслаштырылган торак фондының махсуслаштырылган торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү тәртибе һәм муниципаль махсуслаштырылган торак фондында хезмәт урыннары бирелә торган гражданнар категорияләрен билгеләү турында»гы карарына (28.05.2007 №64-15, 15.06.2015 №172-47, 16.06.2020 №180-43, №189-44 24.08.2020, 145-23 от 23.08.2023 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 10.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10.4. Түбәндәге категорияле гражданнарга аерым тәртиптә хезмәт торак урыннарын хосусыйлаштыру хокукы бирелә:

- җирле үзидарә органнарына сайлап куелган вазифаларга сайланганнар;
- муниципаль хезмәткәрләр, башка хезмәткәрләр һәм җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре;
- Азнакай муниципаль районы эчке эшләр бүлекчәләре хезмәткәрләре;
- Азнакай муниципаль районы муниципаль предприятиеләре хезмәткәрләре.

Азнакай муниципаль районы территориясендә урнашкан муниципаль (дәүләт) учреждениеләр зур ихтыяҗ кичерә торган белгечләр (хезмәткәрләр), шулай ук җирле үзидарә органнары, муниципаль (дәүләт) учреждениесе чакыруы буенча эшкә килгән башка шәһәр гражданнары:

- сәламәтлек саклау;
- мәгариф;
- спорт;
- мәдәният,
- социаль яклау,

- халыкны эшкә урнаштыру һәм эш белән тәэмин итү буенча өлкәләрендә».

1.2. 2 нче кушымтаны, әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2025 елның 29 сентябрендәге №9-2 карарына №2 кушымта

Торак фондында махсуслашкан муниципаль фондта хезмәт торак урыннары бирелә торган гражданнар категорияләре исемлеге

Түбәндәге категорияле гражданнарга аерым тәртиптә хезмәт торак урыннарын хосусыйлаштыру хокукы бирелә:

- җирле үзидарә органнарына сайлап куелган вазифаларга сайланганнар;
- муниципаль хезмәткәрләр, башка хезмәткәрләр һәм җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре;
- Азнакай муниципаль районы эчке эшләр бүлекчәләре хезмәткәрләре;
- Азнакай муниципаль районы муниципаль предприятиеләре хезмәткәрләре.

Азнакай муниципаль районы территориясендә урнашкан муниципаль (дәүләт) учреждениеләр зур ихтыяҗ кичерә торган белгечләр (хезмәткәрләр), шулай ук җирле үзидарә органнары, муниципаль (дәүләт) учреждениесе чакыруы буенча эшкә килгән башка шәһәр гражданнары:

- сәламәтлек саклау;
- мәгариф;
- спорт;
- мәдәният,
- социаль яклау,
- халыкны эшкә урнаштыру һәм эш белән тәэмин итү буенча өлкәләрендә».